| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|

| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
|---|---|---|
| 05.11.2020ел. | Алабуга шәһәре | № 24 |

Алабуга муниципаль районы Советының 2013 елның 28 августында кабул ителгән «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү турында " гы 352 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коммерциясез оешмалар турында» 12.01.1996 ел, №7-ФЗ Федераль законның 31.1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының 2013 елның 28 августындагы 352 номерлы «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты өченче затларның хокукларыннан (коммерцияле булмаган оешмаларның милек хокукларыннан тыш) азат булган муниципаль милек исемлеген раслый. Күрсәтелгән исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәт, аны озак вакытка (шул исәптән аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча) социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга озак вакытка файдалануга бирү максатларында гына файдаланылырга мөмкин. Әлеге исемлек массакүләм мәгълүмат чараларында, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә "Алабуга муниципаль районы " муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында мәҗбүри басылып чыгарга тиеш.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р. М. Нуриев